РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

СОВЕТ САТЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

422070, Республика Татарстан, Сабинский район,
С.Сатышево, ул. Советская, 24
тел. (8262) 48-3-31

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

САТЫШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422070, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Сатыш авылы, Совет урамы, 24 йорт
тел. (8262) 48-3-31

e-mail: Sat.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
23.09.2019

КАРАР
№21

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Сатыш авыл җирлеге Советының
“ Сатыш авыл җирлеге Советы
Регламентын раслау турында” 19.12.2009 елгы №15а
карарына үзгәрешләр кертү турында

ТР Саба районы прокуратурасының 10.09.2019 елгы №02-01-20-19 хатына, Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Уставына туры китереп, Сатыш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советының 19.12.2009 елгы №15а карары белән расланган Сатыш авыл җирлеге Советы үзгәрешләр кертү:

1.1.Регламентының 6 нчы бүлеген түбәндәге эчтәлекле 34.1 статья белән тулыландырырга:

1. Сатыш авыл җирлеге башлыгы, район прокуроры, шулай ук Сатыш авыл җирлеге Уставы, закончалык белән вәкаләтле вазыйфаи затлар, Советның ачык һәм ябык утырышларында катнашырга хокуклы.

2. Советның ачык утырышларында Сатыш авыл җирлегендә яшәүчеләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

3. Совет тарафыннан аларның эшчәнлегенә караган сорауларны караганда, башкарма комитет эшчеләре ачык утырышларда катнашырга хокуклы.

4. Әгәр гомуми депутатларның күпчелеге тарафыннан хупланса, Совет җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының утырышта катнашуын таләп итәргә хокуклы.

Катнашу турында таләп, утырышка кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, Совет утырышына чакырылучы вазыйфаи затка утырышның көне, вакыты, урыны, утырышка куелган сораулар турында Совет рәисе тарафыннан хәбәр ителергә тиеш.

5. Утырышны ачар алдыннан, Совет рәисе Совет депутатлары булып тормаучы, утырышта катнашучы затлар турында игълан итә.

6. Утырышка чакырылган һәм катнашучы затлар Совет эшенә тыкшынырга хокуклы түгел. (чыгыш ясарга, белдерү эшләргә, хуплау яки ризасызлык белдерергә)

7. Совет карары нигезендә, чакырылганнарга әлеге Регламент кысаларында чыгыш ясау өчен сүз бирелергә мөмкин.”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге рәсми сайтында

http://saby.tatarstan.ru/rus/ shitsi  адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырырга.

3. Карар рәсми бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Сатыш авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ф.Шафигуллин